# Гаилә язмышы – илебез тарихында.

(Бәйрәм-сценарие)

**Максат**: укучыларда сугыш чоры балаларына,ветераннарга,тыл хезмәтчәннәренә хөрмәт,игътибарлылык,югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү,туган илебезгә,туган җиребезгә мәхәббәтләрен үстерү;нәсел тарихы белән кызыксынырга,аларны буыннан-буынга тапшырырга кирәклекне өйрәтү;патриотик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлау:**бәйрәм эчтәлеген чагылдырган слайдлар,ядкәрләр,шәҗәрәләрдән күргәзмә.

**Бәйрәм барышы.**

- Хәерле көн, укучылар, кадерле кунаклар! Бүгенге бәйрәмебезнең темасы
**“ Гаилә язмышы – илебез тарихында” дип атала.**
**Без сезнең белән гаилә турында бик күп сөйләштек**, әйтегез әле,
нәрсә соң ул, гаилә?
-Дөрес, балалар, - **гаилә** ул без, әти - әниләребез, әби – бабаларыбыз, ир һәм кыз туганнарыбыз.

- **Гаилә**-ул иң олы таянычыбыз иң ышанычлы сыенур урыныбыз.Сез бик матур фикерләр әйттегез.

-Ә **язмыш** нәрсә ул? Сез бу сүзне ничек аңлыйсыз?
- Бик дөрес. **Язмыш** ул – кешенең тормышы , яшәве, аның узган гомер юлы.

- **Илебез** турында нәрсә әйтә аласыз? Без нинди авылда ,нинди районда,нинди республикада яшибез?
- Мин сезнең белән килешәм, бик яхшы.
- **Илебез** ул – без яши торган авыл, район, республикабыз.Туган ил,туган җир төшенчәләре һәркем өчен изге һәм кадерле.Кеше кайда гына булмасын ,нинди генә урыннарны күреп сокланмасын,аның һәрвакыт газиз җире,туган нигезе үзенә тарта.Биредә аның әти-әнисе гомер итә,нәселдәш туганнары яши ,ерак бабаларының каберләре дә шунда.
- Нәрсә соң ул – **тарих**?
- Тарих сүзе сезгә танышмы?

**Тарих** ул – безнең үткәнебез. Сез аны югары сыйныфларда фән буларак өйрәнә башларсыз.
-Димәк, бәйрәмебездә сүз нәрсә турында барыр?
**-Гаилә, язмыш, ил, тарих турында**.
Без һәр класста гаилә шәҗәрәсе төзедек**.**
Әти - әниләр, апалар һәм абыйлар турында иншалар яздык , әтиләр, әниләр белән берлектә бәйрәмнәр үткәрдек.Бүген без гаилә шәҗәрәләре, гаилә ядкәрләре турында сөйләшербез.
-Балалар, әйтегез әле, сез үзегезнең, әби – бабайларыгызның исемнәрен беләсезме?

- Бу синең әбиең кем ягыннан ?
- Ә менә бу әби – бабаларыгыз ничәнче буын була инде сезгә?Әйдәгез әле бергәләп санап китик.

-Ә менә бу сезнең өченче буыныгыз була.

-Балалар, ә кайсыларыгыз карт әби – бабаларыгызның исемнәрен белә?
-Карт әбиләрегез ничәнче буын була инде?
- Ә бу дүртенче буын була.

- Без сезнең белән болар өстендә бик күп эшләдек. Үзебезнең буыннар чылбырын, шәҗәрә төзедек.

Кайберләрегез 5- нче, 6-нчы,хәтта 7 – нче буын әби – бабаларыгызны ачыклап килдегез.

- Ә балалар, без быел нинди зур бәйрәм билгеләп үтәргә җыенабыз?

-Әйе, укучылар, быел Бөек җиңүгә 65 ел тула.Шул уңайдан **нәселебездә** булган Бөек Ватан сугышында катнашкан әби – бабаларыбызның тормыш юлын искә алырбыз. Шушы елларда сезнең кебек сабыйлар булган, тормышның барлык авырлыгын үз җилкәләрендә татыган авылыбызның хөрмәтле кешеләре белән очрашырбыз.Ә нәсел агачының-шәҗәрәсенең иң кадерле кешеләре –дәү әти һәм дәү әни. Без дә үзебезнең нәселебез тарихын зур кызыксыну белән өйрәндек һәм төзегән шәҗәрәләребездән чыгып Бөек Ватан сугышында катнашкан әби-бабаларыбыз белән таныштыруны 2 –а сыйныф укучысы **Сөләйманова Айгөлнең энисе Гөлнара Венеровнадан** башларбыз. Рәхим итегез!Сүз сезгә..
Балалар, игътибар белән тыңлагыз һәм экранга карагыз.



-**Айгөл** әти - әнисе ярдәмендә нәсел җебен ачыклап Республика күләмендә уздырылган “ Шәҗәрә төзи беләсеңме?” бәйгесендә катнашып иң яшь нәсел агачын төзүче буларак диплом белән бүләкләнде. Айгөл әнисе белән Казанга барды.
-**Ранил** ,безне үзең төзегән шәҗәрә белән таныштырып кит әле.
- **Ранил,** син ничәнче буын әби – бабаларыңны ачыкладың?
-Бу эштә сиңа кем ярдәм итте?
-Син безгә кем турында сөйләрсең?
- **Ранил** Бөек Ватан сугышында катнашкан карт әбисе турында сөйләргә әзерләнгән.

-Балалар, ачыклап китик әле**, Ранилның** карт әбисе ничәнче буынга туры килә икән?
-Беренче буын кем?
-Икенче буын кем килә?
-Өченче буын кем ул?
-Карт әбисе Ранилга ничәнче буын булыр иде?

Рәхмәт, Ранил.Син әбиең сөйләгәннәрне яхшылап язып баргансың.Ә ул сездә кадерле истәлек булып саклана икән.




**Әйдәгез,бергәләп 3-а сыйныфы укучыларның чыгышын карап китик.( “ Ложкари”)**

-Ә хәзер тагын бер язмыш, тагын бер гаилә белән танышып китәрбез.2 – б сыйныфыннан **Шайхиев Рифат белән әнисе Гөлсинә Мансуровнага** сүз бирәбез.

_ Рифат, син безгә кем турында сөйләргә телисең?

Хәзер Рифатның әнисенә сүз бирәбез.



-Без, балалар, Бөек Ватан сугышында катнашып, бик күп авырлыкларны җиңгән әби – бабаларыбыз турында тыңлап киттек.

Сез дә укучылар, шәҗәрә төзүне , туганнарыгыз турында мәгълүмат җыюны дәвам итегез.Шәҗәрәләребезне тулыландырып бетергәч,без аларны мәктәп музеена тапшырачакбыз.

**Хәзер сүзебезне 3 а сыйныфы укучыларына бирәбез.**

-Ә хәзер сугыш елларында үзләренең балачакларын уздырган хөрмәтле ветераннарыбызны тыңлап китәрбез.

Авылыбызның иң хөрмәтле, мөхтәрәм **Гыймазовлар** гаиләсен түргә чакырабыз.Рәхим итегез, түргә узыгыз!

Алар үзләренең 7 буынга хәтле нәсел шәҗәрәсен төзегәннәр**.**

**Хәзер үз нәселләре белән безне Фирая Гумаровна таныштырып китәр.Сүз сезгә.**

-Ә хәзер сугыш елларында үзенең балачагын уздырган **хөрмәтле Вагыйз** абыйга сүз бирәбез.

-**Вәгыйз абый,** сугыш башланганда сезгә ничә яшь иде? Шул чорлар турында безгә сөйләп китегез әле.



-Рәхмәт сезгә. Хәзер без рәхәт, тыныч тормышта яшибез.Балачаклары авыр тормышта узган әби – бабаларыбызның кадерен белик, аларга даими хөрмәт күрсәтик.

- Хәзер сүзне кызларга бирәбез.**( Җыр)**
- Рәхмәт.
- Сүзебезне **Нәзилә апа** белән аның оныгы **Артёмга** бирәбез.Рәхим итегез!
- Артём,син кайсы урындыкка утырыр идең? Әбиеңне кайсы урындыкка утыртыр идең?





- Укучылар, күбегез гаилә ядкәрләре турында мәгълүмат җыйды Һәм кайберләрен күргәзмәгә алып килде.

Балалар, бу күргәзмәгә карагыз әле.

- Сез монда гаилә ядкәрләрен күрәсез.

- Менә болар барысы да гаилә ядкәрләре.
- Ә нәрсә соң ул **ядкәр?**

-**Ядкәр** ул буыннан  - буынга саклана торган истәлекле әйберләр.

-Гаиләдә ядкәрләр саклау бик матур традиция булып тора.

Гаилә ядкәрләре белән безне **Илдар, Аидә, Гөлдания** таныштырып китәр.

Рәхмәт балалар. Сез аларны кадерләп саклагыз.

- Менә ,балалар, бик кадерле ядкәр булып өчпочмаклы хат саклана. Бу хат Айгөлнең бабасына фронттан  67 ел элек килгән.
- Укучылар,бу хатны игътибар белән карагыз әле.Кайсыгыз укый ала?

- Ул гарәпчә язылган.Шушы хатны туганнары буыннан-буынга тапшырып, кадерләп саклыйлар.Бүгенге көндә бу хат Айгөлләр гаиләсенең кадерле ядкәре.
- Менә, балалар, сез дә туганнарыгыздан калган истәлекләрне кадерләп саклагыз,аларны  хөрмәт итегез, яратыгыз.
    - Ә хәзер бәйрәмебезнең ахырында без сүзне Раушания Ринатовнага бирәбез һәм аның белән бергә җыр башкарып китәрбез.